КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 11 февраль г.Казань № 115

Казан шәһәрендә Р.В.Ваһаповка
һәйкәл кую турында

Татарстан АССРның халык артисты, күренекле җырчысы Рәшит Ваһап улы Ваһапов исемен мәңгеләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының, Рәшит Ваһапов исемендәге Татарстан Республикасы Иҗтимагый татар мәдәнияте фондының Казан шәһәре Нурсолтан Назарбаев һәм Павлюхин урамнары киселешендә Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе янындагы скверда Рәшит Ваһаповка һәйкәл (алга таба - һәйкәл) кую турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

һәйкәлне балансta тотучыны билгеләүне;

һәйкәл урнаштыру һәм янындагы территорияне төзекләндерү эшләрен башкаруны.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин